ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.11.2025 с. Майдан 14

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 ел N 232-ФЗ Федераль законы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт күрсәтмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 6.6 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Ундүрт яшькә кадәрге ике яисә аннан күбрәк баласы булган хезмәткәргә, унсигез яшькә кадәрге инвалид баласы булган хезмәткәргә, ундүрт яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз анага, ундүрт яшькә кадәрге баласын анасыз тәрбияләүче атага, гаилә әгъзасын яисә I төркем инвалид булган башка туганын караучы хезмәткәргә, коллектив шартнамә нигезендә, хезмәт хакын саклап калмыйча, үзләре өчен уңайлы вакытта 14 календарь көнгә кадәр дәвам итә торган еллык өстәмә отпуск билгеләнергә мөмкин. Хезмәткәрнең язма гаризасы буенча күрсәтелгән отпуск еллык түләүле отпускка кушылырга яисә аерым тулысынча яки өлешләп файдаланылырга мөмкин. Бу ялны киләсе эш елына күчерү рөхсәт ителми.

Муниципаль хезмәткәргә аның язма гаризасы буенча эш бирүче карары белән акчалата түләүне саклап калмыйча бер елдан да артмаган ял бирелергә мөмкин".

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев